**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет «Мальбагушского сельского поселения» Азнакаевского муниципального района**

ул. Нефтяников дом 30 , с. Мальбагуш Азнакаевского муниципального района 423308,

тел 37-7-91, факс 37-7-91

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы «Мәлбагыш авыл җирлеге» башкарма комитеты**

Азнакай муниципаль районы, Мәлбагыш авылы, Нефтчеләр урамы , 30 йорт

тел 37-7-91, факс 37-7-91

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.09.2019 № 42

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар чыгарам:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Мәлбагыш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 150 сумга киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Мәлбагыш авылында зират коймасын алу (ясау), койма өчен материал сатып алу;

- Мәлбагыш, Түбән Якый, Каменка авылларында юлларны кардан чистарту;

- Мәлбагыш, Түбән Якый авылларында җәйге вакытта үлән чаптыру, территорияне җыештыру хезмәтләре;

- бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Халыкара инвалидлар көне», «Яңа ел», «Җиңү Көне " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү;»

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

Мәлбагыш авылында Нефтьчеләр урамы 30 йорт (Башкарма комитетның административ бинасы) ; Мәлбагыш авылы, Җәлил урамы, 2 йорт (авыл мәдәният йорты; түбән яки авылы, Кашапов урамы, 23 йорт ( ФАП ); Каменка авылында Җәлил урамы, 1 йорт мәгълъмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык: И.Ә.Әхтәмова